Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кичү авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

01 ноябрь 2019 ел N 2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Кичү авыл җирлегенең
Нагорное авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Нагорное авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичү авыл җирлегенең Нагорное авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Нагорный авылында су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3 Халык җыенын Нагорное авыл клубы бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Нагорное авылы, Үзәк урамы, 32 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Нагорное авылы, Үзәк урам, 17 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Кичү авыл җирлеге башлыгы Г.П. Туманова